# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Араслан торак пунктында**

**22 ноябрь, 2021 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 ноябрендә 11 сәгатьтә 00 минутта, 2021 елның 22 ноябрендә 13 сәгатьтә 00 минутта этаплап булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

**җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру**:
- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- торак пункттагы территорияне һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту

**авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**
- суэтем башнясы коймасын ремонтлау, материаллар сатып алу
- материаллар сатып алып су челтәрләрен ремонтлау;
- су башнясын лицензияләү буенча әзерлек эшләре, документаль рәсмиләштерү һәм башка эшләр;

**авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**
-янгын сүндерү машинасын, җиһазларын һәм депо бүлмәләрен карап тоту

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 99 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 64, бу 65 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 64 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Араслан торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Араслан авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

**җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру**:

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- торак пункттагы территорияне һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту

**авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- суэтем башнясы коймасын ремонтлау, материаллар сатып алу
- материаллар сатып алып су челтәрләрен ремонтлау;
- су башнясын лицензияләү буенча әзерлек эшләре, документаль рәсмиләштерү һәм башка эшләр;

**авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

-янгын сүндерү машинасын, җиһазларын һәм депо бүлмәләрен карап тоту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова